1918 елның
1 мартыннан чыга

№ 106 (25260), сишәмбе, 11 сентябрь, 2018 ел

Сатуда бәясе ирекле

# Кызыл таң

Республиканың иҗтимагый-сәяси һәм мәдәни басмасы

Оештыручылар: Башкортстан Республикасы Дәүләт җыелышы - Корылтай, Башкортстан Республикасы Хөкүмәте
Гәзит сишәмбе, пәнҗешәмбе, җомга көннәрендә чыга. Интернеттагы адресыбыз: www.kiziltan.ru

12+

18106>
4 665299 181296

*Сайлау-2018*

# “Бердәм Русия” ышанычлы җиңү яулады

Республика халкы мөһим кампаниядә гражданлык активлыгы күрсәтте




Стефания ПОЛКОВА инфографикасы.

**Бердәм тавыш бирү көнендә республика халкы алтынчы чакырылыш Дәүләт җыелышы-Корылтайга һәм урындагы үзидарә органнарына депутатлар сайлады. Барысы 22 сайлау кампаниясе үтте. Корылтайга 110 депутат сайланды. Шуларның яртысы – бермандатлы округлардан, калганнары бердәм сайлау округы буенча. Депутатлар биш елга сайлана, 18 депутат даими нигездә эшләячәк.**

Иртәнге сәгать 8дә Башкортстанда 3426 сайлау участогы эшли башлады. Участоклар ачылган беренче сәгатьләрдә үк республика район һәм шәһәрләрендә активлык сизелде. Сайлаучылар исемлегендә 3 миллион 50 мең 303 кеше теркәлгән. Иртәнге 10 сәгатькә республика халкының 6,3 проценты, ягъни 192 мең 458 кеше сайлаган иде. 19 мең 618 кеше сайлауларда тәүге тапкыр катнашты. Сиксән яшьне узганнар 137 меңнән артык, 100 яшьлек һәм аннан да өлкәнрәкләр 155 кеше тәшкил итә.

**Башкортстан Башлыгы Рөстәм Хәмитов** Корылтай депутатларын сайлауда катнашты.

– Сайлаулар – безнең тарихыбызның мөһим өлеше ул, – диде Рөстәм Зәки улы. – Сайлау алды кампаниясе югары дәрәҗәдә үтте дияр идем. Дәүләт җыелышы-Корылтай республика тормышында зур роль уйный. Депутатлар республика бюджеты, социаль страховкалау, ветераннарга ташламалар мәсьәләләре өчен дә җаваплы. Дәүләт җыелышын оештыруда катнашып, республика халкы шушы мәсьәләләрне хәл итүгә йогынты ясый. Корылтай яңарачак, күп кенә яңа кешеләр пәйда булачак. Алар республика халкы мәнфәгатенә ал-ял белми эшләр дип ышанам.

**Дәүләт җыелышы-Корылтай Рәисе Константин Толкачев** “Башкортостан” дәүләт концерт залында урнашкан 109нчы участокта тавыш бирде. Парламент Рәисе участокка килгән сайлаучылар һәм күзәтүчеләр белән аралашты. Журналистларның сорауларына җавап биреп, Константин Толкачев сайлау кампаниясендә сәяси партияләрнең актив катнашуын билгеләде.

**Республика Хөкүмәте Премьер-министры Рөстәм Мәрданов** та гражданлык бурычын 109нчы сайлау участогында үтәде.

— Бүген республикада яшәүчеләр дөрес адым ясар һәм җаваплы, патриотик рухлы, халкыбыз мәнфәгатьләрендә җитди эшләүче депутатлар сайлар дип ышанабыз, — диде ул.

Сайлау барышын яктыртучы журналистларның матбугат үзәгендә республиканың **Иҗтимагый палатасы рәисе Ольга Панчихина, сәяси партияләрнең Башкортстандагы төбәк бүлекчәләре җитәкчеләре,** политологлар һәм белгечләр очрашулар үткәрде. Алар үзләренең чыгышларында Башкортстанда сайлауларның гадел, көндәшле һәм ачык үтүен, республика сайлау системасының камилләшә баруын билгеләде.

Кичке сәгать 8дә республикада сайлау участоклары ябылды.

**“Бердәм Русия” партиясе Рәисе, Русия Хөкүмәте Премьер-министры Дмитрий Медведев** Бердәм тавыш бирү көне нәтиҗәләре буенча ил төбәкләре белән видеоконференция режимында селектор киңәшмәсе үткәрде. Анда Башкортстан Башлыгы, партиянең Югары советы әгъзасы Рөстәм Хәмитов катнашты.

Партия Рәисе Дәүләт җыелышы-Корылтайга сайлауларның көндәшлек шартларында үтүен билгеләде.

— Алдан исәпләү нәтиҗәләре яхшы, — диде Дмитрий Медведев. — Без сезне сайлау кампаниясен уңышлы үткәрүегез белән котлыйбыз, уңышлар телибез.

— Һәрвакыттагыча, Башкортстан сайлауны үткәрү буенча актив эшләде. Тавыш бирүдә халыкның 50 процентка якыны катнашты, — диде Рөстәм Хәмитов. 55 округның күпчелегендә “Бердәм Русия” партиясе вәкилләре җиңгән. Республикада сайлаулар гадел, үтәкүренмәле, тыныч шартларда үтте.

*(Ахыры 2нче биттә).*

Безнең карашка

# ХАЛЫККА ФАЙДАЛЫ ЭШ-ГАМӘЛЛӘР КИРӘК!

9 сентябрьдә илдә һәм республикада үткән төрле дәрәҗә сайлауларда “Бердәм Русия” партиясеннән кандидатларның хәлиткеч җиңү яулавы нәрсә белән аңлатыла?

**2018 елның иң мөһим сәяси вакыйгаларының берсе — Башкортстан Республикасының Дәүләт җыелышы-Корылтайга сайлаулар, шулай итеп, артта калды. Узган еллардагы кебек үк, күпчелек тавышны “Бердәм Русия” партиясеннән тәкъдим ителгән кандидатлар җыйды. Шулай итеп, VI чакырылыш Дәүләт җыелышы-Корылтайда да “Бердәм Русия” партиясе вәкилләре күпчелек мандатларны алды.**

Урынлы сорау туа: “Бердәм Русия” партиясенең шушы рәвешле ике дистә елдан артык вакыт дәвамында илнең сәяси мәйданында төп әйдәүче көч булып калуы, ул гына түгел, позицияләрен елдан-ел ныгыта баруы, барлык дәрәҗә сайлауларда да аның кандидатлары зур өстенлек белән җиңү яулавы нәрсәгә бәйле соң? Бу җәһәттән күпчелек аналитиклар, экспертлар, хәтта оппозициядә торучы кайбер партия вәкилләре дә, “Бердәм Русия” партиясенең төп уңыш серен ул соңгы дистә елда гомум халык мәнфәгатендә җәелдергән һәм илнең, төбәкләрнең социаль-икътисади үсешендә мөһим әһәмияткә ия колачлы проектлар белән бәйли. “Эшлекле гамәлләр”, “Шәһәр мохите”, “Урындагы мәдәният йорты”, “Балалар спорты”, “Ныклы гаилә”, “Чишмәләр һәм коелар”, “Чиста су” — болар “Бердәм Русия” партиясе башлангычы белән һәр төбәктә, районда, авылда тормышка ашырылучы өстенлекле проектларның берничәсе генә.

*(Ахыры 2нче биттә).*

**“Бердәм Русия” партиясенең төбәк бүлекчәсе секретаре, Дәүләт җыелышы-Корылтай Рәисе Константин ТОЛКАЧЕВ:**

*– Якынча фаразлар буенча республиканың 60 процент чамасы гражданы безнең партия кандидатлары өчен тавыш бирде. Агымдагы елның мартында ил Президенты сайлауларын үткәргәннән соң беркадәр арыганлык сизелә. Әмма мин сайлаулар ышанычлы, яхшы нәтиҗәләр белән һәм халыкның актив катнашлыгында үтте дип уйлыйм. Республиканың 1,5 миллион гражданының сайлауларда катнашуы моны исбатлый.*

## “ГАЗПРОМ” — ЫШАНЫЧЛЫ ДУСТЫБЫЗ

**Республика Башлыгы Рөстәм Хәмитов “Газпром” акционерлар җәмгыятенең Төбәк сәясәте буенча комиссиясенең күчмә утырышында катнашты. Чара “Газпром” төркеме предприятиеләренең республика территориясендәге эшчәнлегенә багышланды.**

— Сезне “Газпром” оештырылуга 25 ел тулу белән котлыйм, — диде Рөстәм Хәмитов чыгышында. — Башкортстанда “Газпром” берничә ярдәмче предприятиеләрне берләштерә. Аларның эшчәнлеге республика икътисады өчен бик мөһим. Биш ел нәтиҗәләре буенча, корпорация җитештерүне үстерүгә, яңа куәтләр булдыруга, торак пунктларга газ кертүгә, инженер инфраструктураларын яхшыртуга 200 миллиард сум акча юнәлтте.

Рөстәм Зәки улы соңгы елларда бу юнәлештә башкарылган эшләргә җентекле тукталды. Атап әйткәндә, былтыр Салаватта акрил кислотасы җитештерү буенча комплекс ачылган, пентан-гексан фракцияләрен изомерга әйләндерү корылмасы сафка кертелгән. Башкортстан Хөкүмәте бу проектларда катнашучыларга 13,5 миллиард сум күләмендә салым ташламасыннан файдалану мөмкинлеге биргән. “Без арытаба да шушы юлдан барырга риза”, — диде республика Башлыгы.

Соңгы елларда республикада автомобильләргә газ тутыручы 16 станция төзелгән, шуның 14е — “Газпром”ныкы. 2020 елга кадәр предприятие янә биш станцияне эшкә кушарга ниятли. Һәм республикада 1200 транспорт чарасы газ ягулыгына күчә алачак.

Социаль партнерлык та “Газпром” белән республика өчен буш сүзләр түгел. Болар — яңа объектлар төзү, инфраструктураны яхшырту, хәйрия проектларында катнашу. “Газпром” ярдәмендә Башкортстанда эре спорт комплекслары төзелә.

Әлбәттә, проблемалар да бар. Шулар арасында торак пунктларга газ кертү мәсьәләсе иң җитдиләрдән санала. Мөмкинлек булуга карамастан, әле республикада 80 мең йорт хуҗалыгы газга тоташтырылмаган. “Тиздән халыкка газ кертергә ярдәм итү программасы эшләнергә тиеш, чөнки гади кешегә бу эшне башкарып чыгу өчен 100-150 мең сум акча табу авырга туры килә”, — диде Рөстәм Зәки улы.

*(Ахыры 2нче биттә).*

## ТАШЛАМАЛАР САКЛАП КАЛЫНДЫ

**Башкортстан Башлыгы Рөстәм Хәмитов “Сугыш, хезмәт һәм Кораллы Көчләр ветераннары турында” Башкортстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү турында” Законга кул куйды. Мәгълүм булуынча, үзгәрешләр Дәүләт җыелышы-Корылтайның 7 сентябрьдә үткән илле бишенче чираттан тыш пленар утырышында тикшерелде һәм депутатлар тарафыннан хупланды.**

Элек социаль ярдәм чаралары гражданнарга пенсиягә чыккач кына бирелә иде. Хәзер законның яңа редакциясе яшь критерийларын саклап калуны күзаллый. 55 яшьтән өлкән хатын-кызлар һәм 60 яшьтән өлкән ир-атлар пенсиягә чыгуга яисә хезмәтен дәвам итүгә карамастан, түбәндәге ташламаларны алачак: хезмәт ветераннарына торак бинасын һәм коммуналь хезмәтләрне түләү буенча ай саен акчалата компенсация, хезмәт ветераннарына ай саен акчалата, озайлы эш стажы булган ветераннарга ай саен акчалата түләүләр, мактаулы исеме булган һәм аерым хезмәтләргә ирешкән ветераннар өчен пенсиягә өстәмәләр.

Закон республика бюджеты исәбенә гамәлгә ашырылачак.

Мәгълүм булуынча, Русия Президенты Владимир Путин ил гражданнарына мөрәҗәгате барышында федераль пенсия ташламаларын саклап калу кирәклеге турында белдерде. Төбәк дәрәҗәсендә тиешле социаль чараларны саклап калу башлангычы белән Дәүләт җыелышы-Корылтайдагы “Бердәм Русия” фракциясе депутатлары чыкты. Әлеге закон 7 сентябрьдә берьюлы өч укуда кабул ителде.

## “ФАНТАСТИК ЧЫНБАРЛЫК” ОСТАСЫНА – 70 ЯШЬ

**Башкортстан Башлыгы Рөстәм Хәмитов М. В. Нестеров исемендәге Башкортстан дәүләт художество музеенда республиканың халык рәссамы, Русия Художество академиясе академигы Сергей Краснов эшләре күргәзмәсе белән танышты.**

Ул рәссамның 70 яшьлек юбилеена багышланган һәм төрле елларда, төрле жанрларда иҗат ителгән рәсемнәрне үз эченә ала.

Сәнгать белгечләре Сергей Красновны республика сәнгате өчен яңа юнәлешкә нигез салучы буларак билгели. Рәссамны “фантастик чынбарлык” вәкиле, аэроландшафт һәм интеллектуаль рәсем остасы, Башкортстанның Русиядәге заманча сәнгатенең тулы вәкаләтле вәкиле дип исәплиләр.

Аның эшләре төбәк, Бөтенрусия һәм халыкара күргәзмәләрдә, шул исәптән, Мәскәү, Италия, Германия һәм АКШта күрсәтелә.

Рөстәм Хәмитов рәссамны юбилее һәм шәхси күргәзмә оештыруы белән котлады.

– Безнең йортта Сергей Борисовичның өч картинасы бар, – диде төбәк җитәкчесе. – Мәскәүдә яшәгәндә, аларга карап, һәрвакыт Уфаны һәм республиканы искә ала идем.

## МӘСКӘҮ ФОРУМЫНДА ЮГАРЫ БӘҺА АЛДЫК!

**Башкортстан Хөкүмәте Премьер-министры Рөстәм Мәрданов җитәкчелегендәге рәсми делегация Мәскәү финанс форумы мәйданчыгында оештырылган чараларда катнашты. Делегация составына финанс министры вазыйфасын башкаручы Лира Игътисамова, шулай ук, финанс министры урынбасары Наталья Калугина керде. Анда узган елда Русия субъектларының салым сәясәте нәтиҗәлелегенә йомгак ясалды.**

Башкортстан Мәскәү һәм Ханты-Манси автономияле округыннан кала, илнең иң нәтиҗәле эшләүче өч субъекты исәбенә керде. Республика беренчеләрдән булып салым сәясәте инструментларын актив файдаланып, салым базасы һәм бюджетка керемнәр үсеше өчен мөмкинлек белән тулы куәтенә файдаланган.

Төбәк, шулай ук, кадастрдан сәүдә һәм офис милке буенча оешма милкенә салым исәбен, 2015 елдан башлап физик берәмлекләр милкенә салым кертелүгә бәйле югары бәя алды. Шулай салым базасы үсешен тәэмин итте. Куәтле автомобильләр (250 ат көче) өчен транспорт салымы буенча ставкага югары бәя бирелде. Дәүләт бурычын киметү һәм бюджет тәэминатын арттыру буенча берьюлы кабул ителүче чаралар белән республикада алып барылучы ташламалар һәм өстенлекләр сәясәтенә уңай бәя бирелде.

Республиканың рейтинг торышына еллык керемнең дифференцияләнгән күләме исәбенә патентлы салым системасының җәлеп итүчәнлеген арттыру; бюджетка салым бурычын киметү буенча алып барылган актив эш йогынты ясады.

**Үз хәбәрчебез.**

**График буенча кул кую вакыты — 15.00**
**Гамәлдә кул куелды — 14.50**

# “ГАЗПРОМ” — ЫШАНЫЧЛЫ ДУСТЫБЫЗ

(⇨ Башы 1нче биттә).

Шулай ук экология проблемалары турында да онытырга ярамый. Бу җәһәттән бигрәк тә Салаваттан зарланучылар күп. Газга түләүдә бурычлар арту проблемасы да хәл итүне көтә.

Утырыш барышында төрле мәсьәләләр турында фикер алышынды. Рөстәм Хәмитов һәм “Газпром” акционерлар җәмгыяте идарәсе рәисе урынбасары Валерий Голубев онлайн режимда Сибайда автомобильгә газ тутыру станциясе эшенә старт бирделәр.

Шушы ук көнне “Башкортостан” концерт залында “Газпром” ярдәмче предприятиеләренең юбилейларына багышланган тантаналы җыелыш узды. Анда тармак алдынгылары, ветераннар тәбрикләнде, җыелучылар матур концерт карады.

**Резеда ГАЛИКӘЕВА.**

# “БЕРДӘМ РУСИЯ” ЫШАНЫЧЛЫ ҖИҢҮ ЯУЛАДЫ

(⇨ Башы 1нче биттә).

Бердәм тавыш бирү көненә нәтиҗә ясап, Дмитрий Медведев, “Бердәм Русия” яхшы нәтиҗә күрсәтте, дип белдерде.

— Партия тотрыклы чыгыш ясады һәм, якынча мәгълүматлар буенча, сайлаулар үткән Русия субъектларының барлык законнар чыгару органнарында да диярлек алдынгылыкны саклый, — диде ул.

Кичә республика **Үзәк сайлау комиссиясе рәисе Хәйдәр Вәлиев** журналистлар өчен оештырылган матбугат конференциясендә Башкортстанда үткән сайлауларның йомгаклары белән таныштырды.

— Республиканың барлык округларында да сайлаулар үтте дип танылды. Тавыш бирүдә республика сайлаучыларының 49,08 проценты (шәһәрләрдә — 40,57, районнарда – 61,91, Уфада 29,44 процент) катнашты, — диде Хәйдәр Арслан улы. – Сайлауларда ун сәяси партия вәкилләре катнашты. “Бердәм Русия” сәяси партиясенең төбәк бүлекчәсе сайлаучыларның — 58,31, “КПРФ” – 18,80, ЛДПР – 9,96, “Гадел Русия” 5,47 процент тавышын җыйды. Дүрт партия 5 процент киртәсен үткән. “Русия патриотлары”на – 3,95, “Яшелләр”гә 1,98 процент халык тавыш биргән.

Партия исемлеге буенча “Бердәм Русия”дә — 35, “КПРФ”та –11, ЛДПРда – 6, “Гадел Русия”дә 3 мандат. Бермандатлы округлар буенча “Бердәм Русия”дә — 44, “КПРФ”та – 4, “Гадел Русия”дә – 2, “Русия патриотлары”нда – 2, ЛДПРда – 1,“Яшелләр” Русия экология партиясендә 1 мандат. Шулай ук, Сәнәгать округыннан республика парламентына үз-үзен күрсәтүче Айрат Кәримов сайланды.

Алты сәяси партия вәкилләре Дәүләт җыелышы-Корылтай депутаты мандатына ия булды. Җәмгысы “Бердәм Русия”дә – 79, “КПРФ”та –15, ЛДПРда – 7, “Гадел Русия”дә – 5, “Русия патриотлары”нда – 2, “Яшелләр” Русия экология партиясендә – 1, үз-үзен күрсәтүчедә 1 мандат.

Моннан тыш, урындагы үзидарә органнарына депутатлар сайланды. Урындагы сайлауларда республика халкының 54,55 проценты катнашкан. Тавыш бирү нәтиҗәсендә 37 мандатның 32се “Бердәм Русия”дә, 1се “Русия пенсионерлары партиясе”ндә, дүрт мандат үз-үзен күрсәтүчеләрдә.

**Фәнүз ХӘБИБУЛЛИН.**

# САЙЛАУЛАРДА АЧЫК ИШЕКЛӘР КӨНЕ ДӘ ҮТТЕ

**Дәүләт җыелышы-Корылтайга депутатлар сайлау көнендә мәдәният, сәламәтлек саклау, спорт юнәлешләрендә бик күп файдалы һәм күңелле чаралар оештырылды.**


Автор фотосы.

**Табиб Ирина Сафина сайлаучы Юлия Якупованы кабул итә.**

Башкаланың Калинин районында көзге ярминкәләр гөрләде. Алар Интернациональ һәм Машина төзүчеләр урамнары, Мушников һәм Баландин урамнары чатларында оештырылды. Анда килүчеләргә яшелчә-җимеш, ит, сөт ризыклары, бал тәкъдим ителде.

Сайлау участокларында сәламәтлек үзәкләре эшләп торды. Анда килүчеләрне табиблар карады, төрле юнәлештә медицина тикшерүләре белгечләре эшләде.

Башкаланың Орджоникидзе районындагы 303нче сайлау участогында халыкны Республика табиб-физкультура диспансеры белгечләре кабул итте. Биредә кан басымы, йөрәк, күзләр сәламәтлеген тикшертергә, кайсыбер анализлар тапшырырга мөмкинлек бар иде. Сайлауга килүчеләр бу хезмәтләрдән бик теләп файдаланды.

Уфадагы “Кәрвансарай” сәүдә комплексы алдындагы мәйданда башкала рестораннары һәм кафеларының “Есть!” фестивале оештырылды. Анда 40ка якын туклану предприятиесе катнашты. Алар кунакларга дөнья халыклары ризыкларын тәкъдим итте, осталык дәресләре үткәрде, шулай ук биредә хәйрия аукционнары, концерт оештырылды.

Баймак, Иглин районнарында сайлау участокларына дин әһелләре килде, республика тормышындагы мөһим вакыйга уңаеннан фатыйхаларын бирде.

Кушнаренко районында барлык сайлау участокларында да мәдәни чаралар гөрләп торды. Район үзәгендәге участокта Мәшгульлек үзәге белгечләре халыкны кабул итте. Район Сайлау комиссиясе рәисе Флидә Мөхәммәтҗанова әйтүенчә, нәкъ шундый файдалы һәм күңелле чаралар сайлауларга бәйрәм төсе өсти һәм аларның мәртәбәсен арттыра.

**Резида ВӘЛИТОВА.**

Башкортстан Республикасы Хөкүмәте Аппараты, сөекле әнисе **Вахрамеева Антонида Ивановна** вафат булу сәбәпле, Аппаратның мобилизацион әзерлек бүлеге баш консультанты Вахрамеева Светлана Николаевнаның авыр кайгысын уртаклаша.

# ХАЛЫККА ФАЙДАЛЫ ЭШ-ГАМӘЛЛӘР КИРӘК!

(⇨ Башы 1нче биттә).

Илдә әйдәүче төбәк буларак, бу проектлар кысаларында төзү, төзекләндерү, яңа уңайлыклар булдыру юнәлешендәге эшләр Башкортстанда да киң колач белән алып барыла. Әйтик, “Бердәм Русия” партиясенең Башкортстандагы төбәк бүлекчәсеннән белдерүләренчә, быел гына **“Эшлекле гамәлләр”** проекты кысаларында 204 миллион сумлык эш башкарылачак. Җәмгысы республикада соңгы өч елда сайлаучылар наказлары буенча 2,5 мең объектта төзү һәм төзекләндерү эшләре башкарылган.

Берничә ел элек тормышка ашырыла башлаган **“Шәһәр мохите”** проекты да күркәм нәтиҗәләр белән билгеләнгән. Мәгълүм булуынча, тәүге чорда ул шәһәрләрдә генә тормышка ашырылса, хәзер исә авылларны да колачлады. Шул рәвешле былтыр гына да әлеге проект кысаларында республикада 416 йорт-ихата төзекләндерелгән, аларда яңа спорт һәм балалар өчен уен мәйданчыклары калкып чыккан, эскәмияләр, чүп савытлары урнаштырылган, юлларга һәм тротуарларга асфальт түшәлгән, башка уңайлыклар булдырылган. Янә дә 37 җәмәгать территориясе һәм биш парк төзекләндерелгән. Бу җәһәттән агымдагы елга да зур эш күләме билгеләнгән. Җәмгысы проект кысаларында 137 шәһәрдә һәм торак пунктта 415 ихата һәм 123 җәмәгать территориясендә эш башкарылачак, әлеге максатта 1 миллиард сумнан күбрәк акча юнәлтеләчәк.



Стефания ПОПКОВА инфограммасы.

“Бердәм Русия” партиясенең **“Урындагы мәдәният йорты”** проекты да соңгы чорда бик күп мөһим төзелешләр белән билгеләнде. Аерым алганда, быел проектка 15 мәдәният йорты, кече шәһәрләрдәге биш театр һәм өч балалар һәм яшьләр театрлары катнаша. Аларны төзекләндерү максатында 81 миллион сум акча тотынылачак. Былтыр исә әлеге проект кысаларында 32 мәдәният йорты, кече шәһәрләрдәге алты театр һәм ике балалар һәм яшьләр театрлары төзекләндерелгән.

Башкортстанда “Бердәм Русия” партиясенең **“Балалар спорты”** проекты кысаларында авыл мәктәпләренең спорт залларын реконструкцияләү эше дә киң колач белән бара. Бары тик соңгы дүрт елда гына да 288 спорт залына капиталь ремонт үткәрелгән, 35 бина исә физик культура һәм спорт белән шөгыльләнү өчен яраклаштырылган. Моннан тыш, ачык һавадагы 16 мәйданчык төзелгән. Бу максатта 2014-17 елларда гына да 265 миллион сум акча үзләштерелгән. Быел әлеге проект кысаларында 48 муниципалитетта 35,13 миллион сумлык эш башкарылачак.

Гомумән, “Бердәм Русия” партиясенең төбәк бүлекчәсеннән белдерүләренчә, бүген республикада 14 федераль һәм 18 төбәк проекты тормышка ашырыла.

Әлбәттә, тәү чиратта халык мәнфәгатьләрен кайгыртып, чын мәгънәсендә кешеләр өчен башкарылган бу күләмле эшләр сайлаучылар күзеннән, игътибарыннан да читтә калмый. Һәм, әлбәттә инде, халык аңында, күңелендә “Бердәм Русия” партиясенә карата уңай караш, фикер, хис-тойгыларның да ныгуына булышлык итә. VI чакырылыш Дәүләт җыелышы-Корылтайга узган елларда үткән сайлау нәтиҗәләре дә шуның ачык үрнәге булып тора. Һәм фаразлануынча, алдагы чорда “Бердәм Русия” партиясе илнең сәяси аренасында да, халык арасында да үз позицияләрен тагын да ныгытачак кына. Чөнки ул якын чорда, әле тормышка ашырылучы проектлар белән бергә, яңаларын да җәелдерергә ниятли. Ягъни партия тормышы бертуктаусыз хәрәкәттә. Ә хәрәкәт булган җирдә, һәрвакыт бәрәкәт тә була. Шуңа да вәгъдәләрен һәрдаим эш белән раслап килүче “Бердәм Русия” партиясеннән сайланган депутатлардан ил, төбәк, гомумхалык мәнфәгатендә яңадан-яңа файдалы эш-гамәлләр, мөһим башлангычлар көтик!

**Илдар ФАЗЛЕТДИНОВ.**

## “Законлылык тантана итте”

**Башкортстанда үткән сайлауларга карата Русия политологы Дмитрий Орлов та үз фикерен белдерде.**

– Башкортстандагы хәл Русия төбәкләре өчен гадәти дип әйтер идем, – диде эксперт. – Бу – бердәм булып тавыш бирү, гадәткә кергән традицияләргә тугры булу һәм, һәрвакыттагыча, актив катнашу. Шуңа да активлык күрсәткечләренә һич аптырыйсы юк, көндезге 15 сәгатькә 30 проценттан артык булу – бик яхшы күрсәткеч.

Сайлау алды кампаниясе, миңа калса, “тыныч көндәшлек” шартларында үтте. Шул ук вакытта кампания бик позитив булды дип әйтергә кирәк, оппозиция үзен агрессив тотмады, киресенчә, алар үзләренең альтернатив программаларын тәкъдим итәргә тырышты.

Әлбәттә, шикаятьләр дә, сайлауны оештыруга кагылышлы кимчелекләр дә бар, ләкин аларның характеры да, саны да сайлауларның законлы үтүен шик астына куярлык дәрәҗәдә түгел. Дәүләт җыелышы-Корылтайга сайлаулар, һичшиксез, законлы дип табылачак.

Политолог фикеренчә, Дәүләт җыелышының эшчәнлеге нәтиҗәле булсын өчен барысының да стратегияне аңлавы мөһим. “Төрле партияләр вәкилләренең төбәкне үстерүдәге гомум җаваплылыкны аңлаулары мөһим. Моңардан тыш, әлбәттә, парламентта урындагы власть эшчәнлеген хокукый, законнар нигезендә тәэмин итәрдәй көчле бер партия булуы зарур. Менә шушы шартлар үтәлгән очракта Корылтайның эше дә конструктив, гражданнар өчен аңлаешлы һәм файдалы булачак”.

Издательство “Кызыл таң” — филиал ГУП РБ Издательский дом “Республика Башкортостан”. Учредители республиканской общественно-политической газеты “Кызыл таң” — Государственное собрание — Курултай, Правительство Республики Башкортостан. Издается с 1 марта 1918 года. Выходит во вторник, четверг и пятницу на татарском языке.

**Баш мөхәррир**
**Фаил Камил улы ФӘТХЕТДИНОВ.**
**Мөхәрририят:**
**Илдар Фазлетдинов** (җаваплы секретарь), **Фәнис Гәрәев, Резеда Нуртдинова, Рәфис Сәяхов**, **Олег Төхвәтуллин** (баш мөхәррир урынбасарлары), **Фәрит Фаткуллин.**

Редакциянең һәм нәшер итүченең адресы:
450079, БР, Уфа, Октябрьнең – 50 еллыгы урамы,13, 6нчы кат.
Адрес редакции:
450079, РБ, Уфа,
ул. 50-летия Октября,13,
6-й этаж.
kyzyltan@mail.ru

Гәзит Элемтә һәм массакүләм коммуникацияләр өлкәсендә күзәтчелек буенча Федераль хезмәттә 2008 елның 24 сентябрендә теркәлде.
Теркәлү саны — ПИ №ФС 77-33268
Күләме – 2 басма табак
Гомум тиражы —5102 данә
Заказ № 1505.

Гәзит “Кызыл таң” нәшриятының компьютер цехында җыелды һәм Нефтекама матбугат йорты типографиясендә басылды: 452680, БР, Нефтекама шәһәре, Березовка шоссесы, 4А, тел. (8-34783) 7-07-57.
Газета отпечатана в типографии Нефтекамского дома печати. 452680, РБ, г. Нефтекамск, Березовское шоссе,4А, тел. (8-34783) 7-07-57.

Телефоннар:

| | |
|---|---|
| Кабул итү бүлмәсе — | 272-13-61 |
| баш мөхәррир урынбасарлары — | 272-97-71; 273-50-56 |
| җаваплы секретарь — | 272-74-05 |
| Бүлекләр: | |
| сәясәт, икътисад һәм милли проблемалар — | 272-58-40 |
| әдәбият һәм сәнгать — | 272-35-22 |
| авыл тормышы һәм үз хәбәрчеләр челтәре — | 273-46-19 |
| яңалыклар — | 272-75-68 |
| хатлар һәм социаль мәсьәләләр — | 272-82-07 |
| рәссам — | 272-75-21 |
| реклама — | 272-62-27 |
| маркетинг — | 272-35-70 |
| бухгалтерия — | 273-43-43 |
| тәрҗемәчеләр — | 272-74-52 |
| “Әллүки” журналы — | 272-62-19 |
| “Тулпар” журналы — | 272-67-48 |

Факс — 273-88-01, 272-62-27

Үз хәбәрчеләребез:

| | |
|---|---|
| Тәтешле, Яңавыл, Краснокама, Нефтекама | 8-905-00-49-396 |
| Октябрьский, Бүздәк, Әлшәй, Благовар | 8-937-30-24-087 |
| Борай, Кушнаренко, Дүртөйле | 8-917-80-37-750 |
| Чакмагыш, Илеш | 8-937-34-81-921 |
| Бакалы, Шаран | 8-937-49-35-735 |

*Гәзит чыгышларына карата килгән хатларга җавап бирелми, кульязмалар, фотолар, рәсемнәр рецензияләнми, кире кайтарылмый. Редакциянең консультация бүлеге юк. Авторлар фикеренең редакциянеке белән туры килүе зарури түгел.*

*Реклама һәм игъланнарның эчтәлеге өчен реклама бирүчеләр җаваплы.*

“Кызыл таң”ның индексы:
атнага өч тапкыр басылганыныкы — 50602
атнага бер тапкыр — 31084
“Әллүки” журналы — 50709
“Тулпар” журналы — 73192

Безнең дәүләт банкы реквизитлары:
Издательство “Кызыл тан” филиал ГУП РБ Издательский дом “Республика Башкортостан”
Филиал “Приволжский” банка ВТБ (ПАО) в г. Нижнем Новгороде
р/с 40602810000490003697
к/с 30101810922020000728
БИК 042282728
ИНН 0278066967
КПП 027843006
ОКПО 31226910
ОКВЭД — 58.13.1
Дежур: Д. СӨЛӘЙМАНОВА.

© “Кызыл таң” № 106 (25260). 12+




*Кешеләр өчен эшләргә!*

# “Шәһәр мохите” — авылда!

## Краснокама районында өстенлекле проектларны гамәлгә ашыру нәтиҗәсендә бик күп социаль-мәдәни объектлар яңартылды

**Төрле федераль һәм республика программалары ярдәмендә Башкортстанда торак пунктлар төзекләндерелә, ямьләнә. Соңгы елларда Краснокама районында да бик күп объектлар төзелде, яңартылды.**

“Балалар спорты” проекты кысаларында **Яңа Бура** мәктәбенең спорт залына капиталь ремонт ясалды. Биредә электр челтәре яңартылды, запас ишекләр булдырылды, җылыту системасы, идәннәр яңартылды.

— Спорт залы заманча таләпләргә җавап бирсен өчен аңа күптән ремонт кирәк иде. Бу максатка 744 мең сум акча бүленде, шуның күпчелек өлеше – федераль бюджеттан, — ди мәктәп директоры Зәлифә Петровичева.

Физкультура укытучысы Кирилл Корнилов билгеләвенчә, мәктәп укучыларының күбесе спорт белән актив шөгыльләнә. Баскетбол, волейбол, футбол, хоккей һәм җиңел атлетика буенча секцияләр эшли. Мәктәп командасы ел саен район һәм республика ярышларында призлы урыннар яулый. Укытучылар коллективы һәм укучылар заманча спорт залы барлыкка килүен көтеп алды.


Автор фотолары.

**Яңа Кабан** мәдәният йорты хезмәткәрләре дә сөенеп бетә алмый, алар күптәнге хыялын тормышка ашырды — клуб өчен яңа музыкаль җиһаз сатып алды. Мондый мөмкинлекне аларга “Эшлекле гамәлләр” проекты бирде. Аңа кадәр исә авылда Бөек Ватан сугышында һәлак булганнар истәлегенә куелган обелискны коймалаганнар, урамнарны яктырту мәсьәләсе хәл ителгән.

**Саузбаш** авылы халкы да шат. Биредә “Эшлекле гамәлләр” проекты ярдәмендә Бөек Ватан сугышында һәлак булганнар истәлегенә куелган обелиск яңартылган, ветераннар исемлеге тулыландырылган, мәдәният йорты алды яңартылган.




**Илистәнбәт** авылында “Эшлекле гамәлләр” проекты ярдәмендә авария хәлендәге клуб төзекләндерелгән, идән һәм түшәм яңартылган. Авыл халкының шатлыгы зур, чөнки биредә сәнгать сөйгән, дәртле халык яши. Авылда бәйрәмнәр гөрләп уза.

Район үзәге **Николо-Березовка**да да узган ел әлеге программа кысаларында Төзүчеләр урамында балалар мәйданчыгы төзелде.

Биредә күпчелек яшь гаиләләр яшәгән берничә күпфатирлы йорт урнашкан, шуңа да мәйданчыкта иртәннән кичкә кадәр балаларның шат тавышы тынып тормый. Быел исә ихатага “Шәһәр мохите” программасы ярдәме белән асфальт түшәлде.

Николо-Березовка авыл биләмәсе хакимияте башлыгы Александр Карабут әйтүенчә, эшләр 1,5 миллион сумга төшкән.

— “Шәһәр мохите” проекты ихата һәм җәмәгать территорияләрен төзекләндерүне күзаллый. Әмма җәмәгать территорияләрен төзекләндерү әлегә кадәр шәһәрләрдә генә бара иде. Әлеге юнәлештә халык күпләп яшәгән зур авылларда да эш башлануы яхшы, — ди Александр Владимирович.

Бу — әлеге программа кысаларында район үзәгендә төзекләндерелгән беренче ихата. Киләчәктә программа киңәер, аны гамәлгә ашыруга күбрәк акча бүленер һәм ихаталарыбыз авылларда яшәүчеләр өчен уңайлыракка әйләнер дип ышанабыз. Ихатаны төзекләндерү эшләрен Краснокама юл ремонт-төзелеш идарәсе коллективы башкарган.

Югарыда атап үтелгән эшләр — соңгы айларда башкарганнары гына. Ә моңа кадәр алар күпме булды?! Ә иң сөенечлесе — алар кыска вакытлы программа түгел, ә озайлы проектлар.

**Гөлнара ГЫЙЛЕМХАНОВА, “Кызыл таң”ның үз хәбәрчесе.**
Краснокама районы.